ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 20 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә:
а) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7) сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары төзү, елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү өчен Россия Федерациясе Урман кодексының 9 статьясы нигезендә гражданнарга, юридик затларга урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләрен бирү;»;
б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге органының федераль дәүләт урман контролен (урман күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген һәм урманнарны саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;»;

2) 3 өлештә:
а) 1 пунктта «89 статьясындагы» сүзләрен «81 статьясындагы $18^2$ пунктында, 89 статьясындагы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта җөмлә башына «Россия Федерациясе Урман кодексының 81 статьясындагы $18^1$ пунктында,» сүзләрен өстәргә;

в) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урманнарны саклауны гамәлгә ашыру;»;

г) $13^4$ пунктта «3 өлеше» сүзләрен «4 өлеше» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге уникенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

егерме беренче һәм егерме икенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге органының федераль дәүләт урман контролен (урман күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген һәм урманнарны саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге икенче – егерменче, егерме җиденче – кырыгынчы абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан башкарыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге егерме дүртенче – егерме алтынчы абзацларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 03 май
№ 36-ТРЗ